ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗӘЛӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

02.02.2018 г.Мензелинск № 99

**Минзәлә муниципаль район Башкарма комитеты Җитәкчесенең 19.11.2014 елдагы "Минзәлә муниципаль район муниципаль учреждениеләрендә эшләүчеләрнең хезмәтенә түләүне арттыру турында"гы №1165 карарына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 15.12.2017 елдагы № 1000 карары нигезендә

КАРАР ЧЫГАРАМ:

Минзәлә муниципаль район Башкарма комитеты Җитәкчесенең 19.11.2014 елдагы "Минзәлә муниципаль район муниципаль учреждениеләрендә эшләүчеләрнең хезмәтенә түләүне арттыру турында"гы №1165 карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:
карарның 1 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

1. 2018 елның 1 гыйнварыннан билгеләргә:

Минзәлә муниципаль район Башкарма комитеты җитәкчесенең түбәндәге карарлары белән җайга салына торган хезмәткә түләү шартлары булган Минзәлә муниципаль район учреждениеләрендә эшләүчеләргә вазифаи окладка өстәп, авыл җирендә эшләгән өчен түләүләргә һәм стимуллаштыру характерындагы түләүләргә (башкарылган эшләрнең сыйфаты һәм премия түләүләреннән тыш) 14 процент күләмендә өстәмә түләү:

24.08.2010 елдагы "Минзәлә муниципаль районының муниципаль учреждениеләрендә эшләүчеләрнең хезмәтенә түләү шартлары турында"гы №1135;

28.12.2012 елдагы "Минзәлә муниципаль районының муниципаль мәдәният учреждениеләрендә эшләүчеләрнең хезмәтенә түләү шартлары турында"гы №1480.

Татарстан Республикасы
Минзәлә муниципаль район
Башкарма комитеты җитәкчесе
вазифаларын башкаручы А.Г.Гатина.